ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КРАСНОСЕЛЬСКИЙ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422700, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Биектау тиемер юл станциясе поселогы, Совет ур., 13

СОВЕТ КРАСНОСЕЛЬСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422700, Республика Татарстан, Высокогорский район,
п. ж/д ст. Высокая Гора, ул. Советская, 13

тел./факс 8(84365) 2-35-82, e-mail: Ksel.Vsg@tatar.ru

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

**11 август 2020 ел** **№ 172**

**«Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законы нигезендә, ачык тыңлаулар нәтиҗәләре буенча, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Советы,

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Советының 2019 елның 12 декабрендәге 152 нче номерлы карары белән кабул ителгән «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1) 6 статьяның 1 пунктын түбәндәге эчтәлектәге 20 пунктча белән тулыландырырга:

«20) Россия Федерациясе гражданлык законнары нигезендә үз белдеге белән төзелгән корылманы җимерү турында карар кабул итү, рөхсәтсез корылманы җимерү яисә аны, җир белән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрендә, территорияне планлаштыру документларында, яисә федераль законнарда билгеләнгән капиталь төзелеш объектлары параметрларына мәҗбүри таләпләргә туры китереп, капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзүнең, реконструкцияләүнең чик параметрларына туры китерү турында карар кабул итү.»;

2) 51 статьяның 5 пунктын түбәндәге эчтәлектәге 8 абзац белән тулыландырырга:

«-Россия Федерациясе гражданлык законнары нигезендә үз белдеге белән төзелгән корылманы җимерү турында карар кабул итү, рөхсәтсез корылманы җимерү яисә аны, җир белән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрендә,

территорияне планлаштыру документларында, яисә федераль законнарда билгеләнгән капиталь төзелеш объектлары параметрларына мәҗбүри таләпләргә туры китереп, капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзүнең, реконструкцияләүнең чик параметрларына туры китерү турында карар кабул итә .»;

3) 71 статьяны түбәндәге эчтәлектәге 4 пункт белән тулыландырырга:

«4. Үз вәкаләтләрен даими булмаган нигездә гамәлгә ашыру өчен җирлек Советы депутатына эш урынын (вазыйфасын) саклап калу гарантияләнә, аның дәвамлылыгы Татарстан Республикасы законы нигезендә муниципаль берәмлек уставында билгеләнә һәм җыелма рәвештә аена ике көннән ким һәм 6 эш көненнән күбрәк була алмый.»;

4) 93 статьяның 3 пунктын төшереп калдырырга;

5) 98 статьяның 5 пунктын төшереп калдырырга;

2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Башлыгына әлеге Карарны Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсенә әлеге Карар кабул ителгән көннән 15 (унбиш) көн эчендә дәүләт теркәвенә җибәрүне йөкләргә.

3. Әлеге карар дәүләт теркәве узганнан соң Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Башкарма комитеты бинасында Биектау тимер юл станция поселогы, Совет урамы, 13 йорт адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча «авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда: http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча рәсми рәвештә басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) мизгелдән үз көченә керә.

Совет рәисе
Красносельский авыл җирлеге Башлыгы Р.Г.Кәлимуллин